**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

16 август 2023 ел № 14

2023 елның 1 яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге халкының «2023 елның 1 яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2023 елның 1 яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2023 елның 25 августынна дә соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Билгеләргә
- үткәрү срогын – 1 көн;
- үткәрү вакытын – 2023 елның 25 августта сәгать 10.00;
- үткәрү урынын – Тукай районы, Мәләкәс авылы, Үзәк урамы, 27А йорты (Мәләкәс авылының мәдәният йорты, тамашачылар залы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресын – Тукай районы, Мәләкәс авылы, Яшлек урамы, 20 йорты, (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатька кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2023 елның 25 августына кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2023 елның 1 яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев